
ГОД ЦИФРОВИЗАЦИИ В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНДА ЦИФРЛАШТЫРУ ЕЛЫ

Г.Тукай ис. Мөслим урта гомуми белем бирү мәктәбе

# Тукай ялкыны

“ Туган телне сөючеләр” пресс-центры Декабрь, 2023 нче ел №3





**Марсель Хәернас улы Бакиров** — татар галиме, әдәбиятчы, фольклорчы, тюрколог, КДУ профессоры, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Кол Гали исемендәге халыкара премия лауреаты.Ул 1933 елның 10 декабрендә Татарстанның Мөслим районы Мөслим авылында укытучы гаиләсендә дөньяга килә. Марсельгә 3—4 яшь булганда аның әтисе Хәернас ялган донос буенча репрессиягә дучар була.1956 нче елны Казан дәүләт университетын тәмамлый.1956-1966 елларда Уфада "Кызыл таң" газетасында эшли.1966–1969 нче елларда Казан дәүләт университетында аспирантурада укый.1972 нче елда Төрки һәм татар шигыренең эчке ритмик-интонацион хасиятләрен һәм канунннарын экспериментал юл белән тикшерүгә багышланган кандидатлык диссертациясен яклый.1999 нчы елны «Гомум төрки поэзиянең яралуы һәм иң борынгы формалары» дигән темага докторлык диссертациясе яклый.1970–2015 елларда Казан Федераль университетының татар әдәбияты кафедрасында эшли.2012 елдан алып бүгенге көнгә кадәр Татарстан Фәннәр Академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институтның халык иҗаты бүлегендә эшли.

**Бүләкләре, мактаулы исемнәре:**
Татарстанның атказанган фән эшлеклесе
Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре
2023 — Дуслык ордены (Татарстан) — ирешкән хезмәт уңышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

**Фәнни хезмәтләре исемлеге**:
Прототюрки. Изначальная прародина, ранние племена и язык, история и это культура. – Тат.кн. изд. 2019.
Древнетюркская поэзия: неразгаданные тайны устного и письменного творчества наших предков. – Казань: Татарское книжное издательство, 2014.
Феномен параллелизма древнейших мифологических теонимов» (2012)
Татарский фольклор. – Казань. "Ихлас", 2012.
Татарский фольклор. Казань, 2008.
Свадебные обряды и их поэзия татар. – Казань: Слово, 2007.
Путешествие в мир поэзии. Из истории перехода от фольклора к письменному стиху. – Тат.кн. изд. 2003.
Шигърият бишеге: Гомум төрки поэзиянең яралуы һәм иң борынгы формалары. Монография. – Казан: Мәгариф, 2001.
Генезис и древнейшие формы общетюркской поэзии.Монография – Казань:Магариф, 2001.






## Мәктәп яңалыклары...

Танылган фольклорчы, галим-әдәбият белгече, филология фәннәре докторы, КФУ профессоры Марсель Бакировның 90 яшьлек юбилее уңаеннан мәктәбебездә 8а сыйныф укучылары өчен «Якташыбыз, мәшһүр әдәбият галиме Марсель Бакировка-90 яшь» исеме астында әдәби тәрбия сәгате үткәрелде. Марсель Бакиров, әле дә татар халкына үз ачышларын бүләк итә, ул тырышып эшли һәм җәмәгатьчелектә чын кызыксыну уята торган монографияләр чыгара. Хөрмәтле галим ярты гасыр диярлек Казан дәүләт университетының, хәзерге Казан федераль университетының татар әдәбияты кафедрасында эшләгән. Әдәбият теориясе, әдәбият белеменә кереш сүз, шигырь теориясе, татар халык авыз иҗаты кебек төп курслар алып бара. Ул 450дән артык басылган хезмәт авторы, шуларның 7се монографияләр. Шулай ук М.Х. Бакиров халык авыз иҗаты буенча программа һәм дәреслек авторы. 2012 елда ул татар фольклоры монографиясен бастыра, ул татар халкының рус телендәге фольклоры турында ватан һәм милли фәндә беренче монографик хезмәт булып тора. Шулай ук, чарада катнашучылар игътибарына «Әдәбият галименә 90 ел» күргәзмәгә күзәтү оештырылды. Бүген Марсель Бакиров "Таткультресурсцентр" ДБУда эшли. Марсель Хаернасовичны юбилее белән котлыйбыз! Сезгә сәламәтлек, им инлек һәм һәрнәрсәдә уңышлар телибез!



14 нче декабрь көнне , Татарстан Халыклар дуслыгы йортында, күпмиллэтле якшәмбе мәктәпләре һәм белем бирү эчтәлегенең этно-мәдәни компоненты булган мәктәп укучылары фестиваленең йомгаклау туры һәм гала-концерты узды. Чарада мәктәбебезнең «Тукай бизәкләре» хореография ансамбле (җитәкчесе О.С. Нуруллина) 2 нче урын яулады һәм акчалата премия белән бүләкләнде.Әлеге фестивальдә барлыгы 1120 бала катнашты. Алар өч яшь категориясендә хореография, вокал, халык иҗаты номинацияләрендә җиңү өчен көрәштеләр. Проектның зона этаплары Казанда, Әлмәттә һәм Чаллыда узган иде..

***ОЛПАТ ШӘХЕС ҺӘМ ОЛУГ ГАЛИМ***
***(әдәби-биографик очерк)***

Кәгазьгә язып куелмаган шундый бер канун бар: әгәр сәнгатьнең төрле өлкәләрендә талантлар үзләрен яшьтән үк күрсәтә алсалар, фән дөньясында, бигрәк тә филология гыйлеме өлкәсендә, гадәттә кеше зур уңышларга бары тик күп еллар буе тынгысыз хезмәт нәтиҗәсендә генә ирешә ала. Минем бүгенге сүзем әнә шундый дистә еллар буе тырыш хезмәте белән зур уңышларга ирешкән күренекле галим Марсель Хәернас улы Бакиров турында.

Үз эшенә чын күңелдән бирелгән кешеләр тормыш-яшәешнең максатын үзләренең эш-хезмәтләрендә, чын мәгънәсендә аны иҗади һәм нәтиҗәле итеп алып баруда күрәләр. Алар үзләре сайлап алган өлкәгә шулкадәр ихлас күңелдән бирелгән булалар ки, мондый шәхесләр өчен иң зур шатлык һәм тормышның бөтен күркәмлеге дә нәкъ менә шул өлкәдә хезмәт итүдә була. Алар үз тормышларын шул хезмәттән, шул өлкәдә иҗат итүдән башка күз алдына да китерә алмыйлар. Бу - чын иҗат кешеләре өчен уртак бер сыйфат. Мәсәлән, бөек француз язучысы Оноре де Бальзак еш кына: “Минем тормышымның иң зур вакыйгалары ул -минем язган әсәрләрем”, - дип әйтә торган булган. Минем белүемчә, Марсель Бакиров өчен дә тормышның максаты һәм бөтен мәгънәсе ул — фән, үзе яраткан халык авыз иҗаты, шигырь һәм шигърият дөньясы, гомумтөрки поэзиянең башлангыч чорын һәм иң борынгы жанрларын күпьяклы итеп өйрәнү, шул өлкәдә яңадан-яңа ачышлар ясау. Әлеге шәхеснең үткән тормыш баскычларын, минемчә, нәкъ менә аның иҗади ачышлары белән бәйләп карарга кирәктер. Ә аның ачышлары, халкыбызның ихтирамын яулап алган фәнни хезмәтләре исә шактый күп һәм саллылар: ул хезмәтләр нинди генә зур галимнәрне дә кызыктырырлык, сокландырырлык дәрәҗәдә язылганнар. Әгәр без бүген Марсель Бакиров хезмәтләренә зур бәя бирәбез икән, без аның бу уңышларга авыр тормыш һәм озын хезмәт юлы үтеп килгәнлеген дә истә тотарга тиешбез. Булачак галим 1933 елның 10 декабрендә Мөслим авылында (хәзерге район үзәге) укытучы гаиләсендә туган. Аның әтисе Хәернас тирә-якта танылган бик укымышлы кеше һәм математика укытучысы була. 1935-36 елларда ул хәзерге Зәй районының Югары Баграж авылында мәктәп директоры булып эшләгән, мәктәпнең һәм колхозның берләштерелгән парткомы секретаре вазифасын башкарган. Күп эшләрдә ул үзе башлап йөргән, бик актив оештыручы булган. Ә әнисе Фатыйма апа башлангыч классларда укытучылык иткән. “Балачагым - бал чагым" диләр безнең халыкта. Бу балачакның рәхәтлектә үтүенә, матур булып хәтердә калуына ишарәли, әлбәттә. Ә менә Марсельнең балачагы ачысын-төчесен татып, күп кыенлыклар күреп, бик кырыс һәм авыр шартларда үтә. Иң хәтәре шул: Марсельгә 3-4 яшь вакытта аның әтисе Хәернас абзыйны репрессиялиләр. Ул болай була.

Бервакыт, көз көне урып-җыю вакытында, партком секретаре булып эшләүче Хәернас абзый, басуга колхозчыларның ничек эшләүләрен тикшерергә баргач, боларга әйткән:

- Без дәүләт биргән планны үтәргә тиешбез. Уңыш яхшы күренә, планны үтәвебездә шик юк. Әмма ашлык уңган дип әрәм-шәрәм итмәгез, басуда бер башак та калдырмагыз. Чынлыкта сез үзегезнең өлешне калдырасыз бит. Үз өлешегез күп булсын дисәгез, башак калдырмагыз, - дигән. Менә шул сүз аны гаепләргә җитә калган. Ул елларда НКВД органнарына бер кечкенә генә сигнал килә икән, эш тирәнгә китә торган булган. Хәернас абзыйдан көнләшеп йөри торган берәү аны шул чакта “чаккан”: “Партком секретаре хөкүмәткә каршы сөйли. Хөкүмәт өлеше - эскертләрдә, сезнең өлешегез - җирдә калган башакларда дип колхозчылар күңеленә коткы сала. Аларның мәнфәгате белән хөкүмәт интересларын капма-каршы куя, дәүләткә каршы агитация алып бара” дип, ялган документ-“донос” язып җибәргән. Шул җитә калган. Хәернас абзыйны “халык дошманы” дип гаепләп, алып киткәннәр һәм бернинди адвокатсыз-яклаучысыз, тикшерү дә ясап тормыйча, бары “тройка” карары белән генә хәл итеп, ике ай ярым эчендә атканнар.

Ирен алып киткәч, Марсельнең әнисе Фатыйма апаны да тынычлыкта калдырмаганнар, аны өч баласы белән һәм сигез айлык корсаклы хәлендә, кыш уртасы дип тормыйча, мәктәп карамагындагы өйдән куып чыгарганнар. Гаиләнең аянычлы хәленә соңыннан сугыш елларындагы авырлыклар килеп ялганган. Ул елларда Фатыйма апаны, башлангыч класс укытучысы буларак, Мөслим районының иң еракта кечкенә авылларына җибәрә торган булганнар. Ә Марсель белән абыйсы Марс Мөслимдә икесе генә, бер караучысыз калганнар, үз көннәрен үзләре күрергә тиеш булганнар. Менә шул вакытта татыйлар да инде алар "Нужа бабай шулпасын". Өйдә бары ике җан - әле буыннары да ныгып җитмәгән ике малай, өй эче табагач болгасаң да бернинди чүпрәк-чапрак кисәге эләкмәслек шыр ялангач. Ярдәм итүче, киңәш бирүче беркем юк. һәркемнең үз кайгысы. Беркем дә “халык дошманы” балалары белән аралашырга атлыгып тормый. Өйдә бөтен карап торган нәрсәләре - елның елында диярлек кысыр кала торган бер чирләшкә генә кара сыер. Аны карарга, ашатырга-эчертергә кирәк. Салам ашатып кына аның нинди сөте булсын?! Җитмәсә, әниләре башка авылда торып укыта дип, өй артындагы бәрәңге бакчасын да кисеп алып, районның бер түрәсенә биргәннәр. Бәрәңге утыртырга рөхсәт юк. Нишләмәк кирәк - язларын “халык дошманы”ның ике малае, ишек алдындагы бәләкәй генә җирне казып, шунда бәрәңге утырталар. Аннан күпме генә бәрәңге чыксын инде?! Әниләренең эш хакы да - аена бер пот бәрәңге алырлык кына. Һәм менә шул кытлык хәле үзен аларга кышларын шактый сиздерә дә. Малайлар алдына кырыс проблема килеп баса: булган хәтле бәрәңгене кыш буена ничек җиткерергә? Авыр хәлдән чыгу өчен болар мәктәпкә иртән ашамыйча гына йөри башлыйлар. Эчнең “боргалавы”на түзеп, көнозын, 5-6 сәгать буена, хәтта кайчакта кичкә кадәр мәктәптә булалар. Ә мәктәптән кайткач, учак ягып, казанга күп итеп су салалар, аның өстенә сыер биргән бер кружка сөтне өстәп, бер-ике бәрәңге әрчеп салалар да озак кына кайнаталар. Бәрәңге, изелеп, юка гына элпә булып төпкә ята. Һәм ике ач малай сөттән төсе аз гына үзгәргән шул “баба шулпасы”н тәлинкә-тәлинкә чөмерә башлыйлар. Хет корсак тулсын дип, бер утыруда алтышар-җидешәр тәлинкә су чөмерәләр. Корсаклары, кем әйтмешли, бет үтерерлек хәлгә килә. Ә соңыннан иң тәмлесе – төпкә яткан, вакланып-изелеп беткән бәрәңгене ашыйлар. Әнә шулай, тәүлегенә бер генә ашап, көн артыннан көн үтә. “Нужа бабай” малайларны сынавын, ничек яшәргә кирәклеген өйрәтүен дәвам итә. Язларын болар кардан ачылган колхоз җире өстеннән черек бәрәңге җыеп, кәлҗәмә пешергәлиләр. Ә бер язны, ялланып, көрәк белән бер кешенең 25 сутыйлык бакчасын казып чыгалар. Шуның өчен алган бер пот онны, һәр пешергән саен суга 5-6 кашык кына салып болгату исәбенә, ике айга кадәр диярлек җиткерәләр. Кайчакта нужасы да, шатлыгы а бергә йөри бу тормышның. Язарга каләм-карандаш юк вакыт. Язу перосының бик кыйммәтле вакыты. Яки каз каурыен очлап, каурый каләм белән язасың, яки бик авырлык белән генә табылган пероны юкаыннган тал чыбыгына киертеп һәм җеп белән бәйләп куеп, корымнан ясалган карага манып язасың. Язарга дәфтәре дә юк. Электән калган китапларның юл араларында калган ак җиренә язарга туры килә. Сугыш вакытында Мөслимгә төрле шәһәрләрдән эвакуация белән берничә семья килгән була. Марс белән Марсель шуларга утын кисәргә алыналар. Эт кебек арып, бер атна буена биш кубометр утын кисәләр, аны ярып, өеп куялар. Шуның өчен кулларына тегеләр биргән өр яңа ике кап перо килеп керә. Малайлар икенче көнне үк шул пероларны үз классларындагы балаларга илтеп тараталар. Әй, шатланалар шулчак Мөслим балалары! Бу Марсель балачагындагы бик сирәк туры килгән иң матур мизгелләрнең берсе була.

Тулырак: https://tatar-inform.tatar/news/k-ch-komnar-bet-ez-marsel-bakirov-mo-a-riza-t-gel-vatanym-tatarstan



Татарстан Республикасында Милли мәдәниятләр һәм традицияләр елы кысаларында педагог оештыручы Р. З. Бухарова "Әкиятләр дөньясында"дигән класс сәгате үткәрде. Чара барышында 5а сыйныф укучылары рус халык әкиятенең "Репка" персонажларын ясадылар.Геройлар реалистик килеп чыкты, ә әкиятне тәкъдим итү балалар өчен кызыклы һәм мавыктыргыч шөгыль булды.



2 декабрьдә безнең илдә РФ Конституциясе көне билгеләп үтелә. Быел төп закон кабул ителүгә 30 ел тула. Бу дата белән бәйле рәвештә Г.Тукай ис.Мөслим урта гомуми белем бирү мәктәбендә район башлыгы Хуҗин Альберт Робертович катнашында унынчы сыйныф укучылары өчен сыйныф сәгате үткәрелде. Очрашуда төп законның һәр граждан өчен мөһимлеге турында фикер алыштылар, мисалларда кеше хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыруны карадылар. Альберт Робертович РФ Конституциясе статьяларын көндәлек тормышта куллану кирәклеге турында сөйләде. Сыйныф сәгатен тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы Әсәдуллина Йолдыз Рәис кызы үткәрде.



Инвалидлар декадасы кысаларында бүген "Мизгел" яшьләр үзәгендә «Без бергә» дип исемләнгән хәйрия марафоны узды. Әлеге чарада мәктәп директоры Г. М. Галеева катнашты



**ЧУРА БАТЫР**

Дастаннарның «Чура батыр» исемлесе Казан ханлыгы чорына карый һәм әлеге татар дәүләтенең Явыз Иван IVгә каршы героик көрәшен, җиңелү фаҗигасен эпос теле һәм эпик образлар ярдәмендә бәян итеп, тасвирлап бирә. Әлеге әсәрнең, ориенталист И. Березин төзеп чыгарган «Турецкая хрестоматия» (К., 1862) җыентыгындагы татар текстыннан тыш, казакъ, нугай, .Польша татарлары, шулай ук өлешчә башкортлар арасында язып алынган һәм төрле басмаларда дөнья күргән төрле милли версияләре билгеле.

«Чура батыр»ның казакъ варианты («Шора батыр» һәм аның этисенә багышланган «Нәрек» дастаннары) эпик «кырык нугай батыры» циклына кертеп карала һәм «нугай» төшенчәсе ошбу очракта казакъларның да кыпчак-нугай катламына нисбәтле героик үткәненә бәйле рәвештә кулланыла. Эпос белгече В. М. Жирмунский фикеренчә, бу әсәрләр казакълар һәм нугайлар күченеп йөргән, үзара аралашкан Җаек буе һәм дә аннан аргы биләмәләрдә—Көнбатыш Казакъстанда иҗат ителгәннәр. Шуңа күрә дә аларда казакъ тарихына хас булган калмыкларга каршы көрәш мотивы Чура батырның эшчәнлеген-көрәшен билгеләүче төп коллизия итеп тасвирланган да (В. М. Жирмунский. Тюркский героический эпос.—Л.: Наука, 1974.-С.394-395, 515-516).


Фольклорчы-археограф, профессор Әбүбәкер Диваев әле генә аталган ике казакъ эпос-дастанында, шулай ук әсәрнең үзе язып алган архаик вариантында Чура батыр туган төбәгеннән барып калмыкларга каршы көрәшеп йөргән Казан каласы да асылда Идел буендагы без белгән кала түгел, ә Җидесу төбәгендә, Алмалыкта урнашкан һәм элек Казан дип аталган башка шәһәр булган дип исәпли. Казакъ дастаннарын һәм Ә.Диваев вариантын махсус өйрәнгән академик А.С.Орлов та билгеле бер дәрәҗәдә аның фикеренә кушыла һәм, калмыкларны куып җибәргәч, Чура батырның Казанга хан булып кайтуы Идел буе чынлыгы белән ярашмый дип карый (А.С.Орлов. Казахский героический эпос.—М.: Изд.АН СССР, 1945.—С. 111—112). Казан татарларының беркайчан да калмыклар белән сугышмавына игътибар иткәндә һәм «Нәрек», «Шора батыр» (вар. «Чора батыр») дастаннарында тасвирланган тарихи чынлыкның күбрәк Урта Азия регионына туры килүен исәпкә алганда, ошбу галимнәрнең фикере дөреслеккә шактый якын булып тоела. Чөнки XV—XVIII йөзләрдә нәкъ менә Урта Азиядә, ягъни көнчыгышган хәзерге Казакъстан белән чиктәш Жунгариядә хакимлек иткән сиратлар (калмыклар) үзләренең тирә-ягындагы биләмәләргә, шул исәптән Җидесу төбәгенә дә, кат-кат яу чабып торган.

Нәрек (вар. Нәрик, Нарыкбай) белән Шора (Чура) батыр чыккан «тама» исемле ыру да һәм, икенче версия буенча, янә аргын кабиләсе дә («асылым артык аргынмын») Урта Идел буенда түгел, ә көньякта, төгәлрәк әйткәндә, Каспий—Арал диңгезләре арасында һәм Җидесу төбәген дә эченә алучы Урта Азия регионында күченеп йөргән (В.В.Вострое, М.С.Муканов. Родоплеменной состав ирасселение казахов.—Алма-Ата: Наука, 1968.—С.69—70; Дамир Исхаков. От средневековых татар к татарам нового времени.—К., 1998.—С. 154, 158—159). Һәм, «Шора батыр» дастанында әйтелгәнчә, тамалылар Жидесуда урнашкан Казан исемле калада да тәпләнгән булган. (Сүз уңаенда өстик: Казан дип исемләнгән, яисә әлеге сүз кушылып ясалган географик атамалар, шул исәптән торак пунктлары хәзер дә Казакъстанның төрле регионнарында очрый (Т.Җанузак. Казакъ топонимикасы.— Алматы: Дайк-Пресс, 2007.—101, 282 б.). Янә килеп калмыкларга каршы көрәшү өчен тама яугирләреннән төзелгән һәм башында Чура батыр торган хәрбиләрнең ошбу әсәрдә Аксак Тимер гаскәренә тиңләнүе, ягъни баскак әмирнең культ объекты рәвешендә телгә алынуы да бары Урта Азия җирлегенә нисбәт итеп кенә аңлатыла ала. Янә килеп, В.М.Жирмунскийның, В.В.Бартольд белән бер үк фикердә булып, XVI—XVII йөзләрдә мөселман авторларның «мәҗүси» калмыкларны Урта Азия мөселманнарының иң дәһшәтле дошманнары итеп санаганнар» дип әйткән сүзләре дә «Нәрек» һәм «Шора батыр» дигән казакъ дастаннарының төп идеясенә һәм эчтәлегенә тулысынча туры килеп тора. Һәм нәкъ шуңа күрә казакъ версиясендәге «Казанны кяфер («кәпер») алыр дип, әтием утырган алтын так (тәхет) яу кулына калыр дип, чыктым юлга мин» дигән юллардагы «кяфер» сүзен, кайберәүләрчә, русларга карата кулланылган дип карауның да зарурилыгы юк. Ник дигәндә, Урта гасыр мөселман авторларының башка диндәге халыкны «гәүр», «кяфер» дип атаулары ул, гомумән, гадәти күренеш булган. Ләкин шунысы гаҗәп: әлеге өч казакъ дастанындагы төп каһарманнарның исемнәре, хәтта Чураның әти-бабасы исеме дә, шулай ук ыруг-кабилә атамасы да, «Чура батыр» эпосының татар, нугай һәм кырымтатар версияләрендәге исемнәр белән шактый тәңгәл килә. Аерым алганда, һәр ике төркемдә дә Чураның әтисе Нәрык (вар. Нарәң, Нәрең, Нәрик, Нәрек, Нәрыкбай) дип, әнисе—Миңлесылу (вар. Миңле Аруг, Минеылу, Акминде), батыр дусты—Колынчак (вар. Колыншак), Чураның әти-әнисен рәнҗеткән яки аның үзен үтерергә теләгән дошманы Али би (вар. Гали бәй) дип исемләнә. Каһарманның асылы, ягъни ыру-кабиләсе исеме тама (күкес/ көкеш яки аргын кабиләсенең бер өлеше) дип күрсәтелә (Д.Исхаков. Чура батыр кемул?//Идел.—1994.—№9.—Б.17). Бары Нәрыкның төп йорты, туган җире генә төрле регионнарга бәйләп бирелә. Алда исемләнгән казакъ вариантларында ошбу җир тама кабиләсе яшәгән һәм Казан дигән каланы да эченә алган төбәк итеп, татар версиясендә—Дагстан, кырымтатар вариантында—Кырым, нугай һәм Польша татарлары версиясендә Урта Идел буена урнашкан Казан дип күрсәтелә. Бу инде, димәк, сюжет төзелешләрендә һәм конфликтның характерында җирле аерымлыклар булса да, «Чура батыр» эпос-дастанының төрле милли версияләре асылда бер үк уртак чыганактан башлангыч алган һәм үзара «кан алмашкан» дигән сүз. Ләкин аерымланыбрак торучы өч вариантлы казакъ версиясе иң борынгы җирлек булганмы, әллә инде үзара якын булган татар, нугай, кырымтатар һәм Польша татарлары версияләренең берәрсеме—хәзергә моны кистереп әйтү кыен. Дастанның «Чура батыр хикәяте» дип аталган татар версиясе Чура туганга кадәрге хәлләрне сурәтләүдән башланып китә. Аның булачак әтисе, Казый исемле би (бәк) тарафыннан тәрбиягә алып үстерелгән Нарәң батыр Миңлесылу исемле бик чибәр кызга өйләнә. Ләкин аңа Казый бинең энесе гашыйк була һәм, ире югында килеп, аздырырга тырышуы Нарәң кулыннан үтүгә китерә. Күчеп килгән икенче урында да шул ук хәл кабатлана: Хаҗитархан солтанының, Миңлесылуның чибәрлегенә кызыгып, ирен юри йомыш белән читкә җибәрергә һәм моның хатыны белән якынлык кылырга тырышуы шулай ук аның өчен дә үлем белән тәмамлана. Шушы ук традицион мотивның архаиграк варианты белән без янә дастанның «Шора батыр» дигән казакъ версиясендә очрашабыз. Анда Нәрекнең чибәр хатынына калмыкларның Үгезхан исемле ханы кызыгып, ирен «18 айлык юлга» җибәрмәкче була. Әмма ошбу текстта да Үгезханның бозыклыгы үлем белән очлана. Җыеп һәм нәтиҗә ясап әйткәндә, «Чура батыр» дастанының татар версиясе— гомумтөрки тарихи-героик эпосының Казан ханлыгы чорына караучы бер саллы үрнәге. Анда мәркәзебез Казанны һәм дәүләтчелегебезне яклап көрәшкән ил батырларының җыелма образы, ягъни масса күләмендә күрсәтелгән халык батырлыгының үзәк каһарманга бәйләп гомумиләштерелгән героик тибы гәүдәләндерелгән. Шул ук вакытта символик мәгънәгә ия булган Чура батыр образына шәһәрне саклаганда шәһит булган бабаларыбыз фаҗигасенә мөнәсәбәтле трагик мәгънә дә салынган. Халыкның тарихи хәтере һәм сәнгати уйланмага төрелгән социаль-эстетик бәяләмәсе буларак сакланган бу эпос-дастан безне, узганнардан гыйбрәт һәм сабак алып, халкыбызны милләт буларак саклап калу һәм яшәтү идеясенә каһарманнарча хезмәт итәргә чакыра.

"Казан утлары" № 7, 2009





### Дастан «Ак Кубяк»


Относящийся к героико-классической разновидности эпоса данный дастан в конце XIX в. был записан В.В.Радловым у сибирских татар. Запись представляет два варианта: барабинский и тобольский. Известны также хакасский и нугайский варианты эпоса. Оба татарских текста отличаются в достаточной степени художественным совершенством, обилием поэтических, стихотворных строк и в известной мере обработанностью. В то же время эти тексты примечательны тем, что сказочно-мифологические мотивы в них незначительны, а степень историзма сравнительно высока.

В основе эпос-дастана, как это характерно для героико-классического эпоса, лежит конфликт между отдельными народами или племенами. Начало этого конфликта и его основа восходит, видимо, к столкновениям между местными тюркско-кипчакскими племенами (предки сибирских татар) с монголоязычными племена-


facebook.com/groups/sibiriya vk.com/taralar seber-tatar.livejournal.com

188





Марсель Бакировка киләчәктә дә фәнни һәм киң җәмәгатьчелекне үзенең яңа, кабатланмас хезмәтләре белән шатландыруын, тюркология мәйданында һәм милли әдәбият белеме, фольклористика өлкәсендә ары таба да егәрле эшләвен теләп калабыз. Сәламәтлек һәм яңадан-яңа уңышлар аңа



# Укучыларыбыз иҗаты

**7"б"сыйныфы укучылары яза...**
**2024 елга хыялларым...**

2024 нче елга минем хыялым: Хаҗга барырга, кара ташка карарга, 7 жиде тапкыр урап чыгарга гаилә белән, күп мәчетләрдә азан әйтергә, мәчеттә хәзрәт булырга, Пәйгамбәр Мөхәммәд (с.а.в.) күмелгән урынында намаз укырга, зәмзәм суын Аллаһнын ризалыгы белән алып кайтып кардәшлргә эчертергә һәм гаиләмә, күп сүрәләр ятларга, Коръәнне укырга, гарәп телен белергә, догаларны белергә, мәчеттә авылымда аш ☺ үткәрергә, Уразаны тулысынча тотарга. Классташларыма мин саулык, сәламәтлек, озак гомер телим. Мин әнием белән этиемә озын гомер, тазалык, байлык, саулык, сәламәтлек телим.
**Галиев Рамазан**

Мин 2024 елга хыялым: Хаҗга барырга, гаилә белән аны 7 тапкыр урарга, мәчеттә хәзрәт булырга, Пәйгамбәрнең җирлнәнгән урынында намаз укырга, Аллаһнын ризалыгы белән зәмзәм суын Мөслимгә алып кайтып, кардәшләргә эчертергә. Гаиләмә Коръәне укырга, гарәп телен белергә, ураза тотарга, дога белергә дип телим. Классташларыма теләкләрем: чирләмәскә, 4-5леләргә генә укырга, огә-егәләрны әйбәт кенә тапшырырга дип телим.
**Мифтахов Булат, Харисов Ренат**

2024 елда минем хыялларым бик күп .Алар тормышка ашар дип уйлыйм. Минем теләкләрем классташларыма: бәхетле,көчле, матур, әйбәт булсыннар. Әти- әнигә, туганнарга мин озак яшәсеннәр, бәхетле булсыннар, тормышларында гел яхшылык кына булсын дип телим. Хыялларымны тормышка ашыуру өчен мин бик күп эшләргә тиеш, шуның өчен тырыш булырга кирәк. Мин хыялымны тормышка ашыру өчен, тырышып укыячакмын, чөнки минем адвокат буласым килә.
**Вахитов Мөслим**

Яңа ел өчен мин тәмле ризыклар гына түгел,яхшы теләкләр дә телим.Моннан тыш, мин яңа телләрне өйрәнергә, төрле ашханәләрне сынап карарга, кызыклы кешеләр белән танышырга телим. Сәламәт яшәү рәвеше озын гомер һәм бәхет ачкычы дип саныйм. Шуңа күрә мин дөрес ашарга һәм күнегүләр ясарга тырышам. Барлык сыйныфташларым укуларында уңышларга, максатларына ирешүләрен телим. Ә әти-әниемә - сәламәтлек, муллык һәм барлык эшләрендә уңышлар. Минем хыялларым тормышка ашар һәм мин бөтен дөньяны күрә алырмын дип ышанам.
**Сабиров Алмир**

Мин яңа елга мотоцикл телим, ул кыйммәт булса да, мин аны сатып алыр өчен барыбер аңа җыячакмын, әтигә булышып җыячакмын.Мин аларга бу елны онытылмаслык итеп, дуслары һәм якыннары белән үткәрүләрен телим. Алар да без яхшы укысыннар, ата-аналарын тыңласыннар, барлык бәйрәмнәрне күңел биреп, бәхетле итеп үткәрсеннәр дип телиләр. Мин әнигә, әтигә, Амелияга, Азалиягә, бу елны сөенеп уздырсыннар дип әйтәсем килә.
**Аглеев Самир**
Минем хыялым күп бүләкләр һәм уңышлар алырга. Мин классташларыма уңышлар һәм сәләмәт булсыннар, куп акчалар алсыннар дип телим. Мин әти белән әнигә уңышлар , сәламәтлек, бәхет телим.
**Шигаепов Райнур**

Минем хыялларым 2024 нче елга: бүләкләр һәм киләчәктә уңышлы булырга. Татарча көрәштән чемпион булырга, акча эшләргә һәм бәхетле яшәргә. Классташларыма Яңа елга бәхет, күп бүләкләр һәм уңышлар телим .Әти белән әнигә бәхет, шатлык,сәламәтлек һәм озак яшәргә дип телим.

**Ислам Муртазин**

Минем 2024 нче елга, бик зур хыялым бар. Кечкенә генә мастерской булсын иде дип телим. Чөнки мин, тактадан әйберләр ясарга яратам. Минем үземнең классташларыма, иң беренче итеп бәхет, шатлык, сәламәтлек телисем килә.Тәртипләре яхшыга гына үзгәрсен. Ә үземә, эти-әниемә, шул ук иң изге теләкләр телисем килә!

**Закиров Рөстәм**

Һәрбер кешенең тормышта үз хыяллары, максатлары бар. Мин дә читтә калмыйм, һәм минем 2024 елга хыялларым да бар. Быел мин 7 сыйныфны тәмамлыйм, һәм 7 нче сыйныфны яхшы билгеләр белән тәмамлыйсым килә. Классташларыма уңышлар, сәламәтлек, бәхет һәм шатлык телим. Сезнең максатларыгызга омтылуыгызны һәм бер-берегезгә булышуыгызны телим. Мин әнигә һәм этигә сәламәтлек һәм гаиләдә гармония телим.

**Хафизов Руслан**

Мин 2024 елда әбиләр,бабайларга әйбәт яшәргә,сәламәт булырга дип телим. Классташларга әйбәт яшәргә, сәламәт булырга дип телим.
**Латыпов Рамазан**

2024 елга мин үземә брекитка акча җыеп кигертергә телим, мәчеткә барырга, исән-саулык, озын гомер телим һәм Хаҗга барырга телим. Классташларга озын гомер, теләгән теләкләре теләнсен. Әти-әниләргә озын гомер, исән-саулык, шатлык телим. **Багауов Рәфил**

Минем хыялым-квадрокоптер, мотоцикл, сәламәтлек, һәм тизрәк каникуллар житсен.Классташларым сәламәт, тәртипле,чирләмәсеннәр,бишлегә генә укысыннар дип телим.Әни белән эти сәламәт,гел яратып торсыннар,чирләмәсеннәр, матур булып торсыннар, сабыр булсыннар.

**Соломатин Рамазан**

**Яңа ел бит ул могҗиза, Яңа ел — тылсым.**

**Яңа елда һәр кылган эш бәхеткә булсын!**

**Карлар белән бергә җанга ак өмет иңсен.**

**Яңа елда бар җиһанны тынычлык төрсен!**

Яңа ел белән дуслар! Эшләрегез һәрвакыт уң булсын, гөрләп алга барсын, күңелегездә булган мәрхәмәтлелек нуры җаннарыгызны тагын да ягымлы, матур итсен, ялкынландырып бизәп торсын. Йортларыгызга караңгылык, салкынлык, хәвеф-хәтәр кермәсен, бәла-каза килмәсен. Гаилә бәхетегез сүнмәсен, гел балкып торсын!

«Тукай ялкыны", декабрь, 2023 нче ел, Г.Тукай ис.Мөслим урта мәктәбе укучылары газетасы Баш мөхәррир: Гайнетдинова Г.Ф. Корреспондентлар Нуреева Алия, Жаббарова Диана Дизайнер Әсәдуллина Айзилә. Компьютерда җыючы: Галеева Камилә, Миргалимова Эльвина .Гамәлгә куючы: Г.Тукай ис.Мөслим урта мәктәбе укучылар иҗат үзәге Адрес: Мөслим, Тукай 21 Электрон адрес: s2.mus@mail.tatar.ru 100 экземпляр.